СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО

РАЙОНА

РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИЛМӘТ

АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

08 июль 2024ел. № 132

«Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Илмәт авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында»24.08.2023 №107 Илмәт авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында " 23.05.2024 № 637 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Илмәт авыл җирлеге Советы

Карар кабул итте:

1. Илмәт авыл җирлеге Советының 24.08.2023 №107 карары белән расланган Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Илмәт авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: :

1.1. 3.5.8 пунктында:

1) 7 нче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"профилактик визитлар үткәрелергә тиешле контрольдә тотылган затлар исемлеге, яки затлар даирәсен билгеләү критерийлары;».

2) түбәндәге редакциядә абзац белән тулыландырырга:

"Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе, Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасарлары йөкләмәләренә контроль (күзәтчелек) органы житәкчесе тарафыннан затлар даирәсен билгеләү критерийлары кертелгән очракта, профилактик визитлар үткәрелергә тиешле контрольдә тотыла торган затлар исемлеге раслана.».

2.Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Рәисе Р. Т. Мингалеева

Совет Альметьевского сельского поселения Илмәт авыл җирлеге Советы ИНН 1616001591